**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясы $7^1$ өлешен гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 29 сентябрендәге ПУ-940 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Бүлекнең Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затларының Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.15 статьясы 1 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүе;»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны тиешенчә тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

б) 9 пунктта:

дүртенче абзацта «һәм хәрәкәтләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «әзерләгәндә» сүзенә кадәр «проектлар» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «квалификациясен күтәрү һәм стажировкаларын оештыру» сүзләрен «һөнәри үсеше» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының Эксперт идарәсе белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 08 февраль
№ ПУ-91

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ